Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы

# Мәктәп пульсы

№6 ФЕВРАЛЬ

2022 г

## *21 февраль -*
## *Халыкара Туган тел көне*

***И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!***
***Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.***
***И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,***
***Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.***

***Г. Тукай***




*21 нче февраль — һәр милләт, һәр халык өчен бәйрәм көн – Халыкара туган тел көне. Бу көн 2000 нче елда ЮНЕСКО карары нигезендә билгеләп үтелә башлады. Бүген дөнья халыклары 6 мең телдә сөйләшә. Һәркем өчен дөньядагы иң кадерлесе – беренче сөйләшә башлаган ана теле. Халыкара туган тел көнендә барлык телләр дә, тигез дип таныла, чөнки аларның һәркайсы кеше язмышы өчен җавап бирә һәм без аны сакларга тиешбез.*

Эта дата была выбрана в знак памяти событий 21 февраля 1952 года, когда в Дакке, столице нынешней Бангладеш, от пуль полицейских погибли студенты – участники демонстрации в защиту своего родного языка бенгали. Протестующие требовали признать его одним из государственных языков страны.

Родной язык – это выражение самосознания и связи поколений. Он тесно связан с историей этноса, обеспечивает его единство и становится залогом его оригинальности: он формирует неразрывную связь между его носителями и служит основой для народа.

## *И туган тел!*

*Сине Әнкә итеп*
*Йөрәгендә саклый*
*бу халык.*
*Таралган ул...*
*Әгәр син булмасаң,*
*Бетәр иде күптән югалып.*
*Югалмадың,*
*Югалтмадың безне...*

Һәркем өчен дөньядагы барлык телләр арасында иң кадерлесе - тәүге кабат сөйләшә башлаган ана теле. Бу - безнең балачагыбыз, гаиләбез,җәмгыять тәге беренче тапкыр аралашу телебез.

Халыкара туган тел көнендә барлык телләр дә тигез дип танылa, чөнки аларның һәркайсы кеше язмышы өчен җавап бирә, һәркайсы табигый мирас булып тора һәм без аны, һичшиксез, сакларга тиешбез.

Шул уңайдан мәктәптә бик күп чаралар узды.

Шулар арасында патриотик темада узган “Мин Татарстанны яратам!” шигырь бәйгесендә районыбызның төрле мәктәпләрендә белем алучы алтмыштан артык укучысы үзе яшәгән төбәкне, Татарстанны ничек яратуын эчтәлекле чыгышлары аша күрсәтте.

**Рәсимә** Ибраева,
татар теле һәм әдәбияты укытучысы

# Батырлыкта матурлык



***Яшь буынга патриотик тәрбия бирүгә ата-бабалар нигез салган, шуңа күрә безнең бурыч - бу юнәлешне саклау, ныгыту һәм киләчәк буынга тапшыру.***

Арча 2нче номерлы урта гомуми белем мәктәбендә балаларга тәрбия бирүнең төп максаты булып тормышка һәр яктан әзерлекле, үзаңны үстерүгә сәләтле шәхес тәрбияләү тора.

2016 нчы елның сентябреннән мәктәптә Яшь армиячеләр отряды оештырылды. Патриотик хәрәкәт белән мәктәпнең тормыш иминлеге нигезләре укытучысы Илдус Аскаров җитәкчелек итә. Ул - Арча районының «Юнармия» ВВП Штабы начальнигы да. Илдус Равил улы яшь армиячеләрне беренче медицина ярдәме күрсәтергә, Калашник автоматын сүтеп-җыярга, төз атарга, карта буенча ориентлашырга өйрәтә.

“Юнармия” хәрәкәте бер гаилә булып яши. ВКонтакте, Инстаграм кебек социаль челтәрләрдә үз төркемнәре дә бар. Әлеге сайтларда 1000гә якын укучы бер-берсе белән аралаша, элемтәдә тора. Ирешелгән уңышлары белән уртаклаша. Ә уңышлар исә санап бетергесез.

Хәрби уеннарның, конкурс-бәйгеләрнең берсе дә безнең укучыларыбыздан башка узмый. Алар республикакүләм “Алга, Яшь армиячеләр!, “Аҗаган” кебек хәрби уеннарда даими рәвештә призлы урыннар яулыйлар.

Укучылар Җиңү Парадларында, Әфганчылар көнендә, Хәтер көнендә, хәрби патриотик үткән чараларның үзәгендә кайныйлар. Һәлак булучы Геройлар хөрмәтенә веноклар кую эшен горурланып башкаралар. Районда узган башка төр истәлекле көннәрдә дә актив катнашалар. Өлкәннәргә, ветераннарга да шефлык күрсәтәләр, волонтерлык эшләрендә дә үз өлешләрен кертәләр. Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм сугышчы-интернационалист лар катнашында мәктәптә үткәрелгән “Батырлык дәресләре” аеруча игътибарга лаек.

Россия Герое Дмитрий Саф ин исемен йөрткән “Юнар мия” хәрәкәте сафы ел саен тулылана бара. Укучылар хәрәкәт эшчәнлегенә бик теләп кушылалар. Үзләрен чын патриотлар итеп саныйлар һәм әлеге хәрәкәтнең вәкиле булулары белән горурланалар. Алар - Россиянең яшь патриотлары, үз Ватаныбызга ышаныч һәм дөреслекне яклап хезмәт күрсәтәләр.

Мәктәптә тимурчылар отряды эшләп килә. Алар өлкәннәребезгә, ветеран укытучыларга булышлык итәләр. Балалар бакчасын шефлыкка алып, мәктәпкәчә яшьтәге балаларга матур үрнәк күрсәтәләр. Ватанны һәм өлкән буынны хөрмәт итәргә өйрәтәләр.

Укытучыларыбыз көче белән мәктәптә музей-почмак булдырылды. Биредә укучылар мәктәп тарихы, Бөек Ватан сугышы геройларының язмышлары, районыбыз батырлары белән танышалар.

Безнең мәктәпне тәмамлаган, сугышчы – әфганчы Марат Лотфуллинга багышланган экспозиция музейда төп урынны алып тора. Әлеге стендта аның портреты, туганнарына һәм якыннарына язган, хәрби частьтән килгән хатлар урын алган. Укучылар һәм укытучылар коллективының уртак тырышлыгы белән Әфган сугышы эзләре буенча күп материал тупланды. Марат Лотфуллин истәлегенә “Үлемсезлеккә юл” китабы дөнья күрде. Китапта Әфган сугышында батырлык үрнәге күрсәткән укучыбыз Марат Әлтәф улы хакында байтак мәгълүмат бар. Совет гаскәрләрен Әфганстаннан чыгару көненә туры китереп әлеге китапның презентациясе үткәрелде.

Безнең төп бурычыбыз герой-интернационалистлар белән бәйле вакыйгаларны саклап калу.

**Динә** Хәйретдинова,

мәктәп үзидарәсе элемтә министры әгъзасы

# 23 февраль — Ватанны саклаучылар көне

## Батырлык

Безнең заманда кешеләр батырлык эшләргә атлыгып тормыйлар.

Ни өчен икәнен дә белмим. Мин һәрвакыт батырлык кылган кешене күрәсем килде. Ләкин әлегә кадәр очрата алмаган идем. Хәзер андый кешене беләм. Ул-минем әниемнең дәү әтисе, минем бабам! 1940 елның ахырында ул действительныйдан кайткач, Днепропетровскийга  киткән. Алар анда стройкада гына эшләгәннәр.

1941 елның 22 июнендә сугыш башланган.....Аңа да сугышка китергә туры килгән. 1944 елның 24 сентяберендә алар живой языкка барганнар.Алар аннан офицер тотып алып кайтканнар. Сугышта бабаем сопёр булган. Алар барганда җирне минадан чистартып барганнар. Ә кайтканда командирлары мина чистартылмаган юлдан алып кайткан. Ул миналар противотанковый булган. Бер сопёрны кайтып җитәрәк кенә мина бөтенләй очырткан. Ә бабайның минасы шартлаган һәм аның ике күзе  чыккан, бер кулы беләзектән өзелгән, икенче кулының да ике бармагы гына калган.

Шуннан соң аны госпитальгә алып киткәннәр. Сугыштан кайткач та әбиебез аны 43 ел буена караган.Бабаем 1988 елның декабрь аенда үлә.

Әбием белән бабаем чын мәгънәсендә батырлар дип саныйм мин! Мин алар белән бик тә горурланам !

**Гөлүсә** Гарифзянова, 7 сыйныф

«Батырлык! Нәрсә соң ул батырлык? Газиннурлар, Матросовлар кебек күкрәгең белән дошман амбразурасын каплауми, әллә узең ач чакта соңгы сынык икмәгең белән бүлешүме? Кешеләр төрле булган кебек, батырлык та күп төрле шул…»

Ф.Яруллин «Җилкәннәр җилдә сынала»



Эшләп ашагач бигрәк тәмле.
«Яшь армияче»ләр Марат Лотфуллинның әнисе янында.





# Мы будем верою и правдою служить России

15 февраля памятная дата – День памяти воинов-интернационалистов. XX-е столетие часто называют бурным, жестоким. Таким оно стало и для нашей истории. Войны, так или иначе, задели каждое поколение – кто-то сражался с оружием в руках, кто-то провожал близких или оплакивал погибших. День воина-интернационалиста – это день памяти о погибших в Афганистане и всех тех, кто участвовал в урегулировании военного конфликта на территории ближнего и дальнего зарубежья.

14 февраля в районном Доме культуры состоялось праздничное мероприятие, посвящённое Дню памяти воинов-интернационалистов, на котором участвовали ученики нашей школы.

Книжная выставка «Афганистан - живая память».



В нашей библиотеке ко Дню памяти о россиянах, исполнявших служебный долг за пределами Отечества, установленный в память о выводе советских войск из Афганистана как дань уважения советским солдатам и офицерам, не вернувшимся с Афганской войны, подготовлена книжная выставка. На выставке представлены книги памяти о воинах-интернационалистах, погибших в Республике Афганистан.



## урок мужества

В связи с 33-летием вывода советских войск из Афганистана, в целях сохранения памяти о погибших воинах в Афганистане, формирования у учащихся патриотического сознания, чувства верности своему Отечеству. 15 февраля проведены уроки мужества, классные часы и минуты молчания.



## Я – гражданин! Мои права и обязанности

Парламентский урок – совместный проект Государственного Совета Республики Татарстан, Министерства образования и науки и Института развития образования - успешно реализуется с 2009 года. В этом году он проводится уже в четырнадцатый раз. В 2022 году тема парламентского урока связана с правами и обязанностями граждан России и посвящена знаменательной дате – 30-летию Конституции Республики Татарстан.В ходе урока учащиеся познакомились с историей разработки и принятия Конституции РТ, говорили о правах и обязанностях граждан, решали правовые задачи и получили ответы на



## Секреты дружного класса

В Арской детской школе искусств состоялся районный этап республиканского конкурса родительских комитетов «Секреты дружного класса». Цель конкурса – выявление и популяризация лучших практик взаимодействия образовательных организаций и родительских комитетов в воспитании школьников.
Все участники конкурса представили на суд жюри выставку творческих работ, визитку, а также защитили проект.
Честь нашей школы с достоинством отстояли ученики 7 Б класса и их родители.



## Воспитать человека

25 февраля в нашей школе прошёл муниципальный этап республиканского конкурса профессионального мастерства классных руководителей. "Воспитать человека" в рамках республиканского конкурса "Лучший работник сферы воспитания и дополнительного образования".
Основной задачей конкурса является развитие профессионального сообщества специалистов в области воспитания.
Все участники конкурса показали свое профессиональное мастерство и творческий подход к процессу воспитания детей.



25 февраля на стадионе состоялись соревнования по лыжным гонкам среди работников образования . Из нашей школы приняли участие Расима Ханифовна, Ралина Фанисовна, Булат Фанилович, Диляра Ягфаровна.



На базе АСОШ №2 учащиеся прошли единый "Урок Цифры" по теме: "Цифровое искусство: музыка и IT"

На уроке познакомились со специалистом IT-лаборатории и группой стажеров, задача которых — научить Робота слышать песни и узнавать их, а на основе полученных данных находить для пользователей те музыкальные композиции, которые им, скорее всего, понравятся.

Музыка — это эмоции, творчество и свобода. Искусственный интеллект — это алгоритмы, математика и четкая структура.



В рамках недели физической культуры,ОБЖ, искусства, технологии, музыки были проведены открытые уроки и мероприятия.



# *Олимпийские игры 1952 года...*

Победа в Великой Отечественной войне имела огромное значение, в том числе, и для отечественного спорта. Именно после нее СССР вошел в олимпийскую семью. Уже через семь лет, в 1952-м, советские спортсмены, среди которых было немало фронтовиков, приняли участие в играх XV Олимпиады в Хельсинки. Дебют получился триумфальным.

На Олимпийские игры в Хельсинки Советский Союз отправил 295 спортсменов - 255 мужчин и 40 женщин. Представители 10 союзных республик участвовали во всех видах олимпийской программы, кроме хоккея на траве. Всего же в Финляндию приехало 4925 атлетов из 69 стран мира. Соревнования проходили с 19 июля по 3 августа. Команда СССР завоевала 71 медаль - 22 золотых, 30 серебряных и 19 бронзовых, заняв 2-е место в неофициальном медальном зачете после команды США, у которой было 40 золотых наград и 76 в сумме. Советскую сборную называли не иначе как «команда фронтовиков». Отстаивать честь страны на мировой спортивной арене поехали люди, пережившие суровые испытания войны - блокаду, фронтовые ранения, ужасы концлагерей. После окончания войны они сумели не только вернуться в спорт, но и добиться невероятных достижений. Первую золотую медаль нашей команде принесла метательница диска Нина Пономарева. Наиболее удачно выступили сборные по спортивной гимнастике, завоевавшие 9 золотых, 11 серебряных и 2 бронзовые медали. А одним их главных героев игр стал капитан команды гимнастов Виктор Чукарин. Игры в Хельсинки вошли в олимпийскую историю и как Олимпийские игры, которые формально не были закрыты. Президент МОК Зигфрид Эдстрем на торжественной церемонии, посвященной окончанию соревнований, произнес большую речь, но забыл закончить ее предписанными Олимпийской хартией словами: «Объявляю Игры XV Олимпиады закрытыми».

**Ралина** Мухутдинова , министр спорта ШУС











**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.

***Дизайнер - верстальщик*** Мингазова Алсу

Фотокорреспондент Хайрутдинова Дина

***Фотокорреспондент*** Ислам Габдрахманов

***Корректор*** Камиль Гарифуллин

***Редколлегия*** Раниль Заляев

***Адрес:*** ул. Мостовая, дом 15

***Сайт школы*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2